| ГЛАВА БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БИЛӘР АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10. 2020 с. Билярск № 2

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 12 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Биләр авылы мәдәният йорты бинасында билгеләргә.

2. 2020 елның 12 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегенең Биләр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Биләр урта гомуми белем бирү мәктәбе бинасында билгеләргә.

3. Биләр елгасының сул як ярында яшәүче гражданнар җыенының беренче этабында катнашу өчен билгеләргә.

Биләр елгасының уң як ярында яшәүче гражданнар җыенының икенче этабында катнашу өчен билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм

түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү;
- техниканы карап тоту (трактор, шартнамә буенча хезмәт өчен түләү);
- күпер һәм җәяүлеләр кичү юлларын карап тоту һәм ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК».

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр авылы, Калинин урамы, 3 йорт; адресы буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр авылы, Ленин урамы, 6 йорт; «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы җирлек сайтында кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы** **Г.Г.Хәбибуллин**